**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3288**
**28.06.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турынд» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 нче карары белән (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3841 нче карары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибенә, 59 пунктның икенче абзацындагы «кире кагылырга мөмкин» сүзләрен «кире кагыла» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин